**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2021 елның 9 нчы нояберennән** **№ 37**

"Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә бюджет процессы турында" нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә бюджет процессы турында "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 6.02.2020 ел, № 135 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::
1.1. Нигезләмәнең 15 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
- 2) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш , тикшереп торуны гамәлгә ашыра;;
1.2. Нигезләмәнең 35 статьясындагы 27 пунктын түбәндәге эчәлекле җөмлә белән тулыландырырга:
- Кредит (заем, облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне кредитор (заемчы) йөкләмәләрен бирү турындагы шартнамәдә үз ягыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларының максатчан кулланылышын тикшереп тору шарты белән бирелә.";
1.3. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасына ,"Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш ", сүзләрен өстәргә;
1.4. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен аларга беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;";
1.5. Нигезләмәнең 41 статьясындагы 1 өлешен, түбәндәге эчтәлектәге, яңа, өченче абзац белән тулыландырырга:
1)Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар турында;;
2) өченче – дүртенче абзацларны дүртенче - бишенче абзацлар дип санарга
2. Әлеге карарны Песәй авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштырып, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштырырга. www.mendeleevsk.tatar.ru Песәй авыл җирлеге " бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советы Рәисе В. И. Мөхәммәтгалеев